ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**29.05.2023ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1599**

Зеленодольск шәһәренең Гоголь, Каюм Насыйри һәм Карл Маркс урамнары буенча транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында

Зеленодольск шәһәрендә Карл Маркс - Заикин урамында сууткәргечне капиталь ремонтлау, Зеленодольск шәһәрендә юл - урам челтәрен ремонтлау буенча эшләр кысаларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елның 29 маенда 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр Зеленодольск шәһәренең Карл Маркс - Заикин урамындагы сууткәргечне капиталь ремонтлау, Зеленодольск шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түбәндәге участокларында юл - урам челтәрен ремонтлау буенча эшләр башкарылган чорда транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча туктатуны гамәлгә ашырырга:

-Гоголь урамы буенча Заикин урамы белән киселештән Белинский урамы белән киселешкә кадәр.

-Каюм Насыйри урамы буенча Октябрь урамы белән киселештән Белинский урамы белән киселешкә кадәр.

-Карл Маркс урамында Гастелло урамы белән киселешендә.

2. 2023 елның 30 маенда 8.00 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр Зеленодольск шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түбәндәге участокларында Зеленодольск шәһәрендә юл - урам челтәрен ремонтлау буенча эшләр үткәрү чорында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча туктатуны гамәлгә ашырырга:

-Гоголь урамы буенча Тынычлык урамы белән киселештән Гастелло урамы белән киселешкә кадәр.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин